| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ГОРОД БАВЛЫ» РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ «БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28.01.2025 Баулы шәһәре №17

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон белән, «Татарстан Республикасында җирләү эше турында «Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары белән, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2025 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» 2025 елның 23 гыйнварындагы 33 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Кушымталар нигезендә, 2025 елның 1 февраленнән Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 9165,37 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

«Баулы шәһәре» муниципаль берәмле
Башкарма комитеты җитәкчесе С.Ю. Соколов

Баулы муниципаль районы
«Баулы шәһәре» муниципаль берәмле
Башкарма комитетының
2025 елның 28 гыйнварындагы
17 номерлы карарына
1 нче кушымта

2025 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлегендә җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт тарафыннан үлгән кешенең иренә, якын туганнарына, башка туганнарына, законлы вәкиленә яисә җирләүне башкару бурычын үз өстенә алган башка затка күрсәтелә торган җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясе

| № п/п | Хезмәтләр атамасы | Хезмәтләр бәясе (сумнарда) |
|---|---|---|
| 1. | Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | – |
| 2. | Үлгән кешене киендерү | 1768,46 |
| 3. | Каберне казу һәм кешене җирләү өчен кирәкле башка әйберләрне бирү һәм китерү | 3766,44 |
| 4. | Үлгән кешенең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка илтү | 1584,94 |
| 5. | Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2045,53 |
| | Барлыгы: | 9165,37 |

---

Баулы муниципаль районы
«Баулы шәһәре» муниципаль берәмле
Башкарма комитетының
2025 елның 28 гыйнварындагы
17 номерлы карарына
2 нче кушымта

2025 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлегендә ире, якын туганнары, башка туганнары яки вафат булган кешенең законлы вәкиле булмаганда яисә алар тарафыннан җирләү мөмкинлеге булмаганда, шулай ук үлгән кешене Эчке эшләр органнары аның шәхесен ачыклаганнан соң аның өендә, урамда яисә башка урында җирләү бурычын үз өстенә алган башка затлар булмаганда, җирләү мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт тарафыннан күрсәтелә торган җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән Исемлеге бәясе

| № п/п | Хезмәтләр атамасы | Хезмәтләр бәясе (сумнарда) |
|---|---|---|

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | – |
| 2. | Мәетне киендерү | 1768,46 |
| 3. | Каберне казу һәм мәетне күмү өчен кирәкле башка әйберләрне бирү һәм китерү | 3766,44 |
| 4. | Үлгән кешенең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка илтү | 1584,94 |
| 5. | Күмү (кабер казу һәм күмү) | 2045,53 |
| | Барлыгы: | 9165,37 |